КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 6 декабрь г.Казань № 1121

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау тәртибе турында» 2009 ел, 31 декабрь, 933 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау тәртибе турында» 2009 ел, 31 декабрь, 933 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 7 июнь, 438 нче; 2010 ел, 24 август, 676 нчы; 2010 ел, 22 декабрь, 1094 нче; 2011 ел, 25 гыйнвар, 41 нче; 2012 ел, 24 октябрь, 901 нче; 2013 ел, 28 март, 211 нче; 2016 ел, 26 август, 594 нче; 2017 ел, 13 июль, 492 нче; 2017 ел, 24 август, 597 нче; 2017 ел, 20 ноябрь, 892 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү тәртибенә теркәлгән 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү тәртибенә
1 нче кушымта

Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү рәвешендә социаль ярдәм күрсәтү чарасы күрсәтелә торган авырулар исемлеге

| Авыруның исеме | МКБ-10 буенча авыру коды |
|---|---|
| Азканлылык | D50.8, D50.9 |
| Аксым-энергетика җитешмәүчәнлеге | E43, E44.0, E45, E46 |
| Туберкулез белән авыручы белән элемтәгә керү яки аны эләктерү мөмкинлеге | Z20.1 |
| Туберкулин пробасына аномаль реакция | R76.1». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин